**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәнгәр авыл җирлеге**
**Советы**

422756, Әтнә муниципаль районы
Олы Мәнгәр авылы,
Совет урамы, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеменгерского сельского поселения**

422756, Атнинский муниципальный район
с.Большой Менгер,
ул. Советская, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2019 ел. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын икенче этабын билгеләргә: Ленин урамы 1 йорттан 89 йортка кадәр, Мәктәп урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр, Пионер урамы 1 йорттан 29 йортка кадәр.

2. 2019 елның 23 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын беренче этабын билгеләргә: Пролетар урамы 1 йорттан 45 йортка кадәр, Татарстан урамы 1 йорттан 40 йортка кадәр, Совет урамы 1 йорттан 20 йортка кадәр.

3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын беренче этабын үткәрү вакыты 23 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенын икенче этабын үткәрү вакыты 24 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны — Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 11 йорт, Олы Мәңгәр авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 16 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Олы Мәңгәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Олы Мәңгәр торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Олы Мәңгәр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт, Иске Мәңгәр авылы, Тукай урамы, 11 йорт, Бахтияр авылы, Ирек урамы, 2 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.К.Тахавиев